Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXII-8**

Балык Бистәсе штп. 24 июль 2018 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2008 елның 11 ноябрендәге “Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан социаль ипотека системасында торак төзелешен тормышка ашыру өчен дәүләт яки муниципаль милек булып торган җир кишәрлекләрен түләүсез бирү турында карар кабул итү тәртибе хакында” гы Нигезләмә турында” XXXIV-4 номерлы карарының көчен югалтуын тану хакында

Муниципаль норматив хокукый актларны законнарга тәңгәлләштерү максатында Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 маддәсенә, Татарстан Республикасының 2018 елның 14 маендагы “ Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында”гы Законына үзгәрешләр кертү хакында ”гы 31-ЗРТ номерлы Законына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30 маддәсенә таянып,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан РеспубликасыБалык Бистәсе муниципаль район Советының 2008 елның 11 ноябрендәге “Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан социаль ипотека системасында торак төзелешен тормышка ашыру өчен дәүләт яки муниципаль милек булып торган җир кишәрлекләрен түләүсез бирү турында карар кабул итү тәртибе хакында” гы Нигезләмә турында” XXXIV-4 номерлы карарының көчен югалтуын танырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов